МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 167/о

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

«11» 10 2016

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 ст., 2010 елның 27 июлендәге "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" № 210-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" № 880 карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын расларга (алга таба – дәүләт хезмәте).

2. "Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе" дәүләт автоном учреждениесен дәүләт хезмәтен башкаручы итеп билгеләргә.

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага шушы боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Интернет" мәгълүмати-

телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының
11.10.2016 № 167/0
боерыгы белән расланды

**Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясының 1 өлешендәге 5.1 пунктында күрсәтелгән объектларның проект документларына дәүләт экспертизасыннан һәм инженерлык тикшеренүләренә карата дәүләт экспертизасыннан кала, Татарстан Республикасы территориясендәге төзелеш объектларының милекчелек рәвешенә, финанслану чыганакларына һәм кемгә мөнәсәбәтле булуына бәйсез рәвештә, аларга карата дәүләт экспертизасын үткәрү вазифасы федераль башкарма хакимият органына яки аңа буйсына торган дәүләт учреждениесенә йөкләнгән объектлардан гайре объектларның проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәте процедурасын билгели.

Бу Административ регламентта шулай ук административ процедураларның вакытлары һәм эзлеклелеге, вазифаи затлар арасында хезмәттәшлек итү тәртибе билгеләнә.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: төзүче, техник заказчы яки аларның кайсы да булса тарафыннан вәкаләт бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче зат (алга таба – Мөрәҗәгать итүче). Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик затның җитәкчесе яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышанычнамә һәм аның шәхесен таныклый торган документлар нигезендә гамәл кылучы зат эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте “Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – “ТР ДЭББИ” ДАУ) тарафыннан күрсәтелә.

1.4. “ТР ДЭББИ” ДАУ урнашкан урыны, аның белешмә телефоннары, электрон почтасы турындагы мәгълүматлар:

Юридик адресы: 420073, Россия, ТР, Казан ш., Шуртыгин ур., 22.

Урнашкан урыны: 420054, Россия, ТР, Казан ш., Габдулла Тукай ур., 125.

“ТР ДЭББИ” ДАУ элемтә телефоннары:

- Казан шәһәре коды: 8 (843);
- “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы: 272-04-94;
- “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы урынбасары: 272-80-83;
- техник хезмәт җитәкчесе: 272-80-83;
- экспертиза хезмәте җитәкчесе: 272-80-83;
- проект-смета документларын кабул итү бүлеге: 272-56-84;
- бәяләмәләр бирү бүлеге: 272-65-14;
- бухгалтерлык исәбе һәм хисапнамә бүлеге: 272-65-60;
- кадрлар бүлеге: 299-78-59.

Татарстан Республикасы шәһәрләрендә “ТР ДЭББИ” ДАУ бүлекләре:

Бөгелмә бүлеге: 423230, Бөгелмә ш., Гашек ур., 4а. Телефоны: (85594) 4-72-55;

Чаллы бүлеге: 423803, Чаллы ш., Чаллы просп., 17А/24 ф. 38. Телефоны: (88552) 33-28-01.

“ТР ДЭББИ” ДАУ электрон почта адресы: expertiza-rt@tatar.ru.

“ТР ДЭББИ” ДАУ турындагы барлык кирәкле мәгълүматларны шушы Интернет-сайтлардан табарга була:

expert.kgts.ru

gosekspertiza-rt.ru

госэкспертиза-рт.рф

gosekspertiza.tatarstan.ru

Дәүләт экспертизасын үткәрү һәм бәяләмәләрне бирүгә карата гаризаларны һәм башка документларны кабул итү вакыты:

Дүшәмбе-Пәнҗемәшмбе: 08.00 – 17.00;

Җомга – 08.00 – 15.45;

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре;

Төшке аш вакыты: 12.30-13.15.

“ТР ДЭББИ” ДАУ биналарына керү кертү һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ нигезендә башкарыла.

1.3.2. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) “ТР ДЭББИ” ДАУ мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) “Интернет” челтәре аша:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://gosuslugi.ru);

“ТР ДЭББИ” ДАУ телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

“ТР ДЭББИ” ДАУ язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

Шушы Регламентның 1.4., 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә алучы мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә таянып күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – ШрК) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2005, № 1, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма оганнарын оештыруның гомуми принциплары турында” № 184-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1999, № 42, ст. 5005, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” № 131-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2003, № 40, ст. 3822, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы “Дәүләт идарәсен камилләштерү системасының төп юнәлешләре турында” № 601 указы (алга таба – № 601 РФ Президенты указы) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы: http://www.pravo.gov.ru, 2012, 7 май);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы “Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында” № 145 карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2007, № 11, 1336 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 16 февралендәге “Проект документларындагы бүлекләрнең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында” № 87 карары белән расланган Проект документларындагы бүлекләрнең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында нигезләмә (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2008, № 8, ст. 744, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендәге "Дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган, электрон рәвештә күрсәтелә торган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле дәүләт биреме (заказы) яки муниципаль бирем (заказ) урнаштырыла торган хезмәтләрнең исемлеген раслау турында" № 729-р әмернамәсе (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте әмернамәсе) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 18, ст. 2679, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының 2007 елның 3 маендагы "Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлык тарафыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлешен контрольлектә тоту өлкәсендә Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы структурасын килештерү тәртибе турында" № 36 боерыгы белән расланган Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлык тарафыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлешен контрольлектә тоту өлкәсендә Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы структурасын килештерү тәртибе турында нигезләмә (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 46, 2007);

Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлыкның 2007 елның 2 июлендәге "Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләренә карата бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм шушы Реестрда булган белешмәләрне тапшыру тәртибе турында" № 186 боерыгы белән расланган Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләренә карата бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм шушы Реестрда булган белешмәләрне тапшыру тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Реестрны алып бару тәртибе турында нигезләмә) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 31, 30.07.2007, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының 2011 елның 20 декабрендәге "Проект документларына дәүләт экспертизасын, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисапның эчтәлеген һәм рәвешен раслау турында" № 584 боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 14, 2012);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 9 декабрендәге "Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең составына, эчтәлегенә һәм аны рәсмиләштерү тәртибенә карата таләпләр раслау турында" № 887/пр боерыгы (алга таба – №887/пр боерык); (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы: http://www.pravo.gov.ru, 2015, 31 декабря);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының 2012 елның 23 мартындагы “Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен шикаять кылу тәртибен раслау турында” № 126 боерыгы (Российская газета, 2012, 1 июнь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 февралендәге “Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесен төзү турында” № 102 карары (алга таба – 20.02.2015 №102 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 17, ст. 0593, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре” № 313 карары (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) (“Татарстан Республикасы карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 28, ст. 0642, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” № 880 карары (“Татарстан Республикасы карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, шушы белешмәләрне кертү аңа нигезләнеп башкарылган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (хәреф, язу хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәгенең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итү һәм аларга тапшыру, аларны констультацияләү тәрәзәсе.

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла (27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 кушымта).

## 2. Дәүләт экспертизасын үткәрү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы (алга таба – дәүләт экспертизасы) | ШрК 49 ст. 4 өл., Нигезләмәнең 12 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы аталышы | “Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – “ТР ДЭББИ” ДАУ) исеменнән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 20.02.2015 № 102 ТР МК карары, Министрлык турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Проект документларына дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе булып проект документларының техник регламентларның таләпләренә һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә, ШрК 48 статьясының 13 өлешенә туры китереп каралган проект документлары бүлекләренең эчтәлекләренә карата таләпләргә туры килүе турында (уңай бәяләмә) яки туры килмәве турында (тискәре бәяләмә), шулай ук инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең (әгәр дә инженерлык тикшеренүләрнең нәтиҗәләре проект документлары белән экспертизага бер үк вакытта җибәрелгән очракта) техник регламентларның таләпләренә туры килүе турында бәяләмә тора. Әгәр дә инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре экспертизага проект документлары экспертизага җибәрелгәнче җибәрелгән булсалар, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең техник регламентларның таләпләренә туры килүе турында (уңай бәяләмә) яки туры килмәве турында (тискәре бәяләмә) бәяләмә экспертизаның нәтиҗәсе булып тора.<br>Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен югалткан очракта, Мөрәҗәгать итүче бу бәяләмәнең дубликатын алырга хокуклы. | ШрК 49 ст. 9 өл., Нигезләмәнең 34, 43 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору чоры | 1. Шушы Административ регламентка карата 3 кушымтада күрсәтелгән документларны Мөрәҗәгать итүчедән алганнан соң 3 эш көне дәвамында “ТР ДЭББИ” ДАУ аларны тикшерә. Тапшырылган документлар законнардагы таләпләргә җавап биргән очракта, гариза теркәлә һәм электрон белешмәләр базасына кертелә.<br>2. 1 пунктта күрсәтелгән вакыт эчендә Мөрәҗәгать итүчегә шушы Административ регламентка карата 2 кушымтада китерелгән рәвештә, дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләмен хисаплап, “ТР ДЭББИ” ДАУ тарафыннан имзаланган шартнамә проекты яисә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылган документларны кабул итүдән баш тарту турында нигезләнгән җавап тапшырыла (җибәрелә) яки аталган документлар карап тикшерелмичә кайтарып бирелергә тиеш.<br>3. Шартнамә нигезендә дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләгәнлекне раслый торган документларны күрсәткәннән соң дәүләт экспертизасы үткәрелә башлый һәм Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү (тапшыру) белән тәгәлләнә.<br>4. Дәүләт экспертизасын үткәрүнең максималь озынлыгы шартнамәдә билгеләнә, объектның катлаулылыгыннан чыгып билгеләнә, ләкин 30 эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел.<br>Бәяләмә дубликатын бирү түләүсез нигездә язмача мөрәҗәгатьне алганнан соң 5 эш көне дәвамында башкарыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | ШрК 49 ст. 7 өл., Нигезләмәнең 21, 22, 28, 43 п. |
| 2.5. Законнар һәм башка төрле норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук | Дәүләт экспертизасын үткәртү буенча Мөрәҗәгать итүче “ТР ДЭББИ” ДАУ, шушы Административ регламентка карата 3 кушымтада китерелгән документларны теркәп, билгеләнгән рәвештәге (шушы Административ регламентка карата 4 кушымта) гаризаны | Нигезләмәнең 13-18, 44, 45 п. |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле, шул исәптән электрон рәвештәге документларның тулы исемлеге, аларны тапшыру тәртибе | тапшыра.<br>Документларның күчермәләре Мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән таныклана.<br>Проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре яңадан (2 һәм аннан күбрәк мәртәбә) дәүләт экспертизасына тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләрне юкка чыгаргач яки уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына капиталь төзелеш объектының конструктив ышанычлылыгына һәм куркынычсызлыгына йогынты ясый торган техник чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгәч җибәрелә.<br>Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документлары, төзүченең яки техник заказчының инициативасы белән, аңа капиталь төзелеш объектының конструктив ышанычлылыгына һәм куркынычсызлыгына йогынты ясамый торган техник чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракта, яңадан (2 һәм аннан күбрәк мәртәбә) дәүләт экспертизасына җибәрелә ала.<br>Тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе өчен нигез булган җитешсезлекләрне кәгазьдә тапшырылган документларны кайтарып алмыйча юкка чыгару мөмкин булган очракта һәм Мөрәҗәгать итүче мондый документларны кайтартып алу турында таләп итмәгәндә, дәүләт экспертизасын үткәрү буенча оешма мондый җитешсезлекләрне юкка чыгару өчен вакыт билгели. Бу очракта дәүләт экспертизасына тапшырылган документлар Мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелми. Аларны эшләп бетергәннән соң Мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасын үткәрү буенча оешмага кертелгән үзгәрешләре | |

| | | |
|---|---|---|
| | белән бергә проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең бер өлешен бу үзгәрешләрне тасвирлаган белешмә белән тапшыра.<br>Яңадан дәүләт экспертизасын үткәртү буенча Мөрәҗәгать итүче “ТР ДЭББИ” ДАУ түбәндәгеләрне тапшыра:<br>- билгеләнгән рәвештә гариза (шушы Административ регламентка карата 4 кушымта), документларны – үзгәрешләр кертелгән проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең бер өлешен теркәп, шулай ук элек аларга карата дәүләт экспертизасы үткәрелгән проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре белән кертелгән үзгәрешләрнең ярашуы, әгәр дә беренче мәртәбә (алдагы) дәүләт экспертизасын үткәргәннән соң Россия Федерациясе законнарына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләренә йогынты ясый ала торган үзгәрешләр кертелгән икән, ул вакытта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә (шул исәптән документларның бүлекләре составына һәм эчтәлегенә карата) туры китереп, капиталь төзелеш объектына карата проект документларын тулысынча;<br>- проектлау буенча бирем (яки аның күчермәсе, документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә кәгазьдә тапшыру Россия Федерациясе законнарында рөхсәт ителсә);<br>- инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата бирем (яки аның күчермәсе, документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә кәгазьдә тапшыру Россия Федерациясе законнарында рөхсәт ителсә);<br>- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә (шул исәптән аталган нәтиҗәләрнең составына) туры китереп инженерлык | |

| | | |
|---|---|---|
| | тикшеренүләренең нәтиҗәләре;<br>- объектны махсус сакланучы табигый территориядә төзү планлаштырылган очракта уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе;<br>- Мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документлар (Мөрәҗәгать итүче техник заказчы һәм (яки) төзүче булмаган очракта), аларда дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы шартнамәне (алга таба – шартнамә) төзү, үзгәртү, башкару, таркату буенча вәкаләтләр махсус сөйләшенергә тиеш;<br>- эшләр башкаручыны проект документларын һәм (яки) инженерлык тикшеренүләрен әзерләү буенча тиешле эш төрләренә кертү буенча үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, башкарылган эшләрне кабул итү актын имзалаган датага гамәлдә булган таныклыклар, – Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу мәҗбүри булган очракта, һәм башкарылган эшләрне кабул итү турында акт (яки аларның күчермәләре, – документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә кәгазьдә тапшыру рөхсәт ителсә);<br>- шушы объект буенча элек бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең күчермәсе.<br>Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын Мөрәҗәгать итүче “ТР ДЭББИ” ДАУ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше “ТР ДЭББИ” ДАУ рәсми сайтында урнаштырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге очракларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (Мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш йөртүче зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турындагы тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар шулай ук Мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре Мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) һәм имзасы белән таныклана. | |
| 2.6. Норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган | “ТР ДЭББИ” ДАУ тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документлар исемлеге:<br>1. Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсендә).<br>2. Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсендә).<br>3. Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсендә).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны | |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны Мөрәҗәгать итүче тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә алу тәртибе, аларны шушы документлар белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшыру тәртибе | алу ысуллары һәм аның тарафыннан тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарәләр һәм башка оешмалар эш итә торган документларны Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норамтив-хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп итеренә торган һәм бу килештерүне дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт экспертизасына тапшырылган проект документларын һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен кабул итүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр санала:<br>а) проект документларында ШрК 48 статьясының 12 һәм 13 өлешләрендә каралган бүлекләрнең булмавы;<br>б) проект документларындагы бүлекләрнең проект документларындагы бүлекләрнең эчтәлекләренә карата ШрК 48 статьясының 13 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве;<br>в) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең ШрК 47 статьясының 6 өлеше нигезендә билгеләнгән составы һәм рәвеше буенча туры килмәве;<br>г) дәүләт экспертизасын үткәрү буенча кирәкле булган, Нигезләмәнең 13-16 пунктларында күрсәтелгән барлык документларны да тапшырмау, шул исәптән инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә карата уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе булмау (проект документлары инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасыннан соң дәүләт экспертизасына җибәрелгән очракта);<br>д) дәүләт экспертизасына тапшырылган проект документларының ШрК 48 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләргә җавап бирми торган зат тарафыннан әзерләнүе;<br>е) нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына җибәрелгән инженерлык тикшеренүләренең ШрК 47 статьясының 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләргә җавап бирми торган зат тарафыннан башкарылуы. | ШрК 49 ст. 8 п., Нигезләмәнең 24, 25 п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату яки күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:<br>1) әгәр дә төзү яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәсә;<br>2) мондый экспертизаны уңай дәүләт экспертизасы яки дәүләти булмаган экспертиза бәяләмәсен алган һәм кабат кулланыла торган капиталь төзелеш объектлары проект документларына карата яки капиталь төзелеш объектларының конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагылмый торган мондый проект документларының модификациясенә карата үткәрелгәндә;<br>3) капиталь төзелеш объектын төзегәндә яки үзгәртеп корганда, шул исәптән проект документларының элек уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган, капиталь төзелеш объектларының конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларын киметми торган аерым өлешләренә карата проект документларының модификациясе кулланылган очракта;<br>4) капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонт ясау өчен әзерләнгән проект документлары өлешләренә карата, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлау буенча әзерләнгән проект документларыннан тыш.<br>Капиталь төзелеш объектын төзү типик проект документларыннан яки мондый проект документларының модификациясеннән файдаланып гамәлгә ашырылган очракта, инженерлык | Нигезләмәнең 8, 23 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | тикшеренүләренең нәтиҗәләре, проект документларына карата дәүләт экспертизасы үткәрелмәүгә карамастан, дәүләт экспертизасына тиешле.<br>5) дәүләт экспертизасы дәүләт экспертизасын үткәрү буенча башка оешма тарафыннан үткәрелергә тиеш;<br>6) документлар түбәндәге таләпләрне бозып тапшырылган очракта:<br>2016 елның 1 сентябреннән башлап тулысынча яки өлешчә федераль бюджет хисабыннан төзелә яки үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектларына карата әзерләнгән проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле булган документлар Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына буйсына торган дәүләт учреждениесенә электрон рәвештә тапшырыла, проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре файдалану мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән белешмәләргә ия булган очраклардан тыш;<br>2017 елның 1 гыйнварыннан башлап проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле булган башка документлар электрон рәвештә тапшырыла, проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре файдалану мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән белешмәләргә ия | |

| | | |
|---|---|---|
| | булган очраклардан тыш. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | 1. Проект документларына дәүләт экспертизасы Мөрәҗәгать итүче хисабыннан башкарыла.<br>2. Дәүләт экспертизасы өчен түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә түләнә.<br>3. Проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү буенча түләү күләме Нигезләмәнең 53-58 пунктлары нигезендә билгеләнә.<br>Дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләмен хисаплаганда өстәлгән бәягә карата салым суммасы исәпкә алына, әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәсә.<br>Яңадан дәүләт экспертизасын үткәргән өчен беренче дәүләт экспертизасын үткәргән өчен алынган түләү күләменең 30 проценты дәрәҗәсендә түләү алына.<br>Капиталь торак төзелеше объектларына карата яңадан дәүләт экспертизасын үткәргән өчен документлар тискәре бәяләмәне алганнан соң 14 көн дәвамында тапшырылган икән, яңадан дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү алынмый. | ШрК 49 ст. 11 өл., Нигезләмәнең 53-60 п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү таләп ителмәячәк. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | № 601<br>РФ Президенты указы |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәне, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза һәм документлар килгән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнар нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр | системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>“ТР ДЭББИ” ДАУ биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, | |

| | | |
|---|---|---|
| итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән файдаланып | шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәренең мәгълүмат ресурсларында, “ТР ДЭББИ” ДАУ рәсми сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.gosuslugi.ru) дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>“ТР ДЭББИ” ДАУ белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу;<br>мөрәҗәгать итүченең “ТР ДЭББИ” ДАУ белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә, – бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә бүлек белгече белән мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә хезмәттәшлек итү озынлыгы 15 минуттан артмый. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата гариза тапшыруны кертеп, күпвазифалы үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.<br>Мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәренең мәгълүмат ресурсларында, “ТР ДЭББИ” ДАУ рәсми сайтында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.gosuslugi.ru) дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат буллу. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт экспертизасын электрон рәвештә үткәрергә мөмкин булган Интернет-сайтларның адреслары шушы Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелде.<br>Интернет-сайтлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:<br>дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризаны, проект документларын һәм дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле башка документларны тутыру һәм шәхси кабинет аша тапшыру;<br>дәүләт экспертизасы барышы турындагы белешмәләрне карый алу мөмкинлеге;<br>дәүләт экспертизасын үткәргәндә ачыкланган җитешсезлекләрне алу, документларның төзәтмәләр кертелгән өлешләрен “ТР ДЭББИ” ДАУ җибәрү;<br>дәүләт экспертизасын үткәргәндә электрон имзадан файдалану.<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы “Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында” № 145 карарының 2 пунктындагы “к” һәм “л” пунктчаларында каралаган | Нигезләмәнең 39 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | чорлар килеп җиткәнче, әгәр дә документлар кәгазьдә тапшырылса, дәүләт экспертизасын үткәрү шартнамәсендә проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең электрон рәвештә тапшырылу мөмкинлеге каралырга мөмкин.<br>Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар оешманың җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат тарафыннан “Электрон имза турында”гы Федераль законда каралган, көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана.<br>Мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасын үткәрү буенча документларны электрон рәвештә җибәргән очракта, дәүләт экспертизасы бәяләмәсе электрон рәвештә бирелергә мөмкин. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәге, күпвазифалы үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Мөрәҗәгать итүченең шушы Административ регламентка карата 3 кушымтада күрсәтелгән документлар җыелмасы белән "ТР ДЭББИ" ДАУ мөрәҗәгать итүе дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен нигез булып тора.

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча дәүләт хезмәтен күрсәткәндә "ТР ДЭББИ" ДАУ түбәндәге тәртипләрне саклый:

1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2. гаризаны һәм теркәлгән документлар җыелмасы белән документларны кабул итү һәм теркәү;

3. ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә электрон рәвештә белешмәләр тапшыру турында гарызнамәләр җибәрү һәм сорала торган документларны (белешмәләрне) алу.

4. дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә (шушы Регламентка карата 3 кушымта) туры китереп, Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулылыгын тикшерү яки документларны кабул итүдән баш тарту;

5. дәүләт хезмәтенең бәясен билгеләү, дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча шартнамә төзү;

6. дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

7. күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең бәяләмәсен төзү һәм теркәлгән рәвештә (бәяләмә дубликатын) тапшыру;

8. техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү;

9. дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру;

10. дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару;

11. бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү;

12. дәүләт хезмәтен яңадан күрсәтү, бәяләмә дубликатын бирү.

Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча блок-схема шушы Административ регламентка карата 1 кушымтада китерелә.

3.1.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә аңа ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

"ТР ДЭББИ" ДАУ белгече Мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алуга бәйле башка мәсьәләләрдә.

"ТР ДЭББИ" ДАУ белгече Мөрәҗәгать итүчене дәүләт хезмәтен алу предметына карата консультацияли, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, рәвеше буенча консультацияләү.

3.1.2. Гаризаны һәм теркәлгән документ җыелмалары белән документларны кабул итү һәм теркәү.

3.1.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки почта аша (кулга тапшыру турындагы тамгасы һәм теркәлгәннәрнең исемлеге белән) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза һәм шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшырылган көннән соң 3 эш көне дәвамында документларны кабул итүче "ТР ДЭББИ" ДАУ белгечләре, шушы Регламентның 3 кушымтасына туры китереп, кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә.

3.1.3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә белешмәләр бирү турында гарызнамәләр җибәрү һәм сорала торган документларны (белешмәләрне) алу.

Техник хезмәт белгече ВЭХС системасы аша түбәндәгеләргә электрон рәвештә гарызнамәләр җибәрә:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан яисә Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан белешмәләр бирелү турында;

Дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар реестрыннан белешмәләр бирелү турында.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләр.

Сорала торган документлар (белешмәләр) белешмәләрне җиткерүче тарафыннан законнарда билгеләнгән чорларда җибәрелгән гарызнамәләр нигезендә бирелә.

3.1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге (шушы Регламентка карата 3 кушымта) нигезендә Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулылыгын тикшерү яки документларны кабул итүдән баш тарту.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулылыгын шушы Регламентка карата 3 кушымтасына туры китереп тикшерү. Кирәкле документларның булмавы, тапшырылган документларның таләпләргә җавап бирмәү фактларын ачыклаганда, “ТР ДЭББИ” ДАУ белгече Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларда ачыкланган җитешсезлекләр турында аңлата һәм аларны юкка чыгару буенча чаралар күрергә киңәш итә.

Кәгазьдә тапшырылган документлар Мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә (дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризадан башка). Электрон рәвештә тапшырылган документлар (дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризадан башка) бәяләмәне теркәгәннән соң кимендә 3 ай дәвамында сакланырга тиеш.

Язмача баш тарту заказлы хат итеп җибәрелә яки Мөрәҗәгать итүченең кулына гаризаны тапшырган көннән соң 3 эш көне дәвамында тапшырыла. Баш тарту турындагы белдерүнамә телефон аша, язмача яки электрон рәвештә дә җиткерелергә мөмкин.

Документлар тулы булмаган очракта, Мөрәҗәгать итүченең язмача гарантиясе булганда, документлар, шул исәптән электрон рәвештә тапшырылганнары да, Мөрәҗәгать итүче язмача гарантия тапшырган вакыттан башлап 10 эш көне дәвамында алар тупланып беткәнчегә кадәр кайтарып бирелми.

Документлар тупланмасы федераль законнарда билгеләнгән таләпләргә (шушы Регламентның 3 кушымтасы) җавап биргән очракта, гариза теркәлә һәм электрон белешмәләр базасына кертелә, дәүләт экспертизасының бәясен ачыклау өчен техник хезмәткә тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза килгән һәм кирәкле документлар тапшырылган вакыттан соң 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрү өчен гаризаны теркәү; дәүләт экспертизасының бәясен ачыклау өчен техник хезмәткә тапшыру яисә дәүләт экспертизасын үткәрү турында баш тарту турындагы карарны җибәрү.

Җаваплы зат – “ТР ДЭББИ” ДАУ техник хезмәте җитәкчесе.

3.1.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү бәясен ачыклау, дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча шартнамә төзү.

Дәүләт экспертизасының бәясе ачыклангannan соң, Мөрәҗәгать итүчегә, “ТР ДЭББИ” ДАУ тарафыннан имзаланган, дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү күләме хисапланган шартнамә проекты (алга таба – шартнамә) җибәрелә (тапшырыла). Шартнамә проекты (шушы Административ регламентка карата 2 кушымта) Мөрәҗәгать итүчегә электрон рәвештә дә җибәрелергә мөмкин.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза килгән һәм кирәкле документлар тапшырылган вакыттан соң 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрүнең бәясен ачыклау һәм шартнамә рәсмиләштерү.

Җаваплы зат – “ТР ДЭББИ” ДАУ техник хезмәте белгече.

3.1.5.1. Шартнамәне хокукый җайга салу Россия Федерациясенең гражданлык законнарында түләүле хезмәтләр күрсәтү шартнамәсенә карата билгеләнгән кагыйдәләр буенча гамәлгә ашырыла.

3.1.5.2. Шартнамәдә түбәндәгеләр билгеләнә:

1) шартнамәнең предметы;

2) дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты һәм аны озынайту тәртибе;

3) дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләме;

4) дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кабул ителгән, кәгазьдә тапшырылган документларны Мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү тәртибе һәм вакытлары, әгәр дә документларны кәгазьдә тапшыру Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителгән булса;

5) аларны бозу тарафларга шартнамәне вакытыннан алда өзү мәсьәләсен күтәрү хокукын бирә торган әһәмиятле бозуга карый торган шартнамә шартлары;

6) шартнамәдән килеп чыга торган йөкләмәләрне башкармаган өчен һәм (яки) тиешенчә башкармаган өчен тарафларның җаваплылыгы.

3.1.5.3. Мөрәҗәгать итүчедән 10 (ун) эш көне дәвамында аның тарафыннан имзаланган дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы шартнамәне һәм анда дәүләт экспертизасын үткәргән өчен каралган түләүне алмаган очракта, дәүләт экспертизасы үткәрелми, ә барлык документлар Мөрәҗәгать итүчегә 3 эш көне дәвамында кайтарып бирелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар шартнамә проектын Мөрәҗәгать итүчегә җибәргәннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрүгә карата шартнамә төзү.

3.1.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.1.6.1. Шартнамәне имзалагач һәм Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү кертелгәнне раслый торган документлар тапшырылганнан соң, шушы объектка беркетелгән, бүлекнең

җаваплы белгече 2 эш көне дәвамында проект документларының бүлекләрен карап тикшерү өчен тиешле бүлекләргә җибәрә.

3.1.6.2. Тиешле бүлек башлыгы проект документларының бүлекләрен бүлек экспертларына яки шартнамә нигезендә экспертизаны үткәрү өчен җәлеп ителгән оешмаларга һәм (яки) белгечләргә, локаль эксперт бәяләмәләрен бирү вакытларын билгеләп, җибәрә һәм мәгълүматны экспертиза объектының карточкасына кертә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар шартнамәне имзалаганнан соң һәм дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү керткәч 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: локаль эксперт бәяләмәсен төзү.

3.1.6.3. Нигезләмәнең 35 пункты нигезендә, дәүләт экспертизасын үткәргәндә проект документларында бәяләмә әзерләргә мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр ачыкланган очракта (белешмәләрнең, тасвирламаларның, хисапларның, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яки тулы булмавы), “ТР ДЭББИ” ДАУ, дәүләт экспертизасы буенча шартнамә төзү вакытыннан алып 10 эш көненнән артмаган чорда, Мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр итә.

Белдерүнамә язмача яки электрон рәвештә дә җибәрелергә мөмкин.

Җитешсезлекләрне юкка чыгару вакыты Мөрәҗәгать итүче аларны алганнан соң 8 эш көненнән артык түгел.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар шартнамәне имзалаганнан соң һәм дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү керткәч 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә җитешсезлекләр турында белдерүнамә җибәрү.

3.1.6.4. Әгәр дә ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләт экспертизасы барышында юкка чыгару мөмкин булмаса яки Мөрәҗәгать итүче аларны билгеләнгән чорда юкка чыгармаса, дәүләт экспертизасын үткәрүче оешма экспертизаны алга таба үткәрүдән баш тартырга һәм, фактта күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләп, шартнамәне вакытыннан алда өзү мәсьәләсен куярга хокуклы, бу хакта, кабул ителгән карарның нигезләрен күрсәтеп, Мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә хәбәр итә.

3.1.6.5. Әгәр дә тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе өчен нигез булган җитешсезлекләрне кәгазьдә тапшырылган документларны кайтарып бирмичә генә юкка чыгарырга мөмкин булса һәм Мөрәҗәгать итүче мондый документларны кайтарып бирү турында таләп итмәсә, ул вакытта әлеге җитешсезлекләр 10 эш көненнән артмаган чорда юкка чыгарыла. Бу очракта дәүләт экспертизасына тапшырылган документлар Мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелми. Аларны җиренә җиткереп бетергәннән соң Мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасын үткәрү буенча оешмага, кертелгән үзгәрешләре һәм әлеге үзгәрешләрне тасвирлаган белешмә (кисәтүләргә җаваплар) белән,

проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең бер өлешен тапшыра.

3.1.7. Күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең бәяләмәсен төзү һәм теркәлгән рәвештә бирү.

3.1.7.1. Экспертлар тарафыннан локаль эксперт бәяләмәсе төзелгәннән соң, алар дәүләт экспертизасы бәяләмәсен төзү өчен "ТР ДЭББИ" ДАУ җаваплы белгеченә тапшырыла. Бер үк вакытта башкару турында белешмәләр дәүләт экспертизасы объекты карточкасына теркәлә.

"ТР ДЭББИ" ДАУ җаваплы белгече уңай (тискәре) бәяләмә төзи һәм аны раслау өчен "ТР ДЭББИ" ДАУ башлыгына тапшыра.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе № 887/пр боерык нигезендә (шушы Регламентка карата 7 кушымта) рәсмиләштерелә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы экспертлар тарафыннан имзалана, "ТР ДЭББИ" ДАУ башлыгы яисә аның вазифаларын башкаручы зат тарафыннан раслана һәм эш башкару тәртибендә теркәү өчен тапшырыла.

Электрон рәвештә әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы экспертлар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана һәм "ТР ДЭББИ" ДАУ башлыгы яисә аның вазифаларын башкаручы зат тарафыннан раслана һәм эш башкару тәртибендә теркәү өчен тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документларны тапшырганнан соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы экспертлар тарафыннан имзаланган һәм "ТР ДЭББИ" ДАУ башлыгы тарафыннан расланган һәм теркәү өчен тапшырылган уңай (тискәре) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.1.7.2. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, теркәлгән документлар Мөрәҗәгать итүчегә яки аның ышанычлы затына тапшырыла, яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе 4 нөсхәдә бирелә. Тискәре бәяләмә – 1 (бер) нөсхәдә.

Бәяләмәне алу буенча Мөрәҗәгать итүче "ТР ДЭББИ" ДАУ – шәхесен таныклый торган документны, Мөрәҗәгать итүченең вәкиле юридик затның законлы вәкиле тарафыннан таныкланган ышанычнамәне һәм шәхесен таныклый торган документны күрсәтергә тиеш.

Кәгазьдә тапшырылган проект документлары, проектлауга карата биремнең күчермәсе, инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре һәм инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата биремнең күчермәсе Мөрәҗәгать итүчегә шартнамәдә билгеләнгән вакытта һәм тәртиптә кайтарып бирелергә тиеш. Аталган документлар электрон рәвештә тапшырылган

булсалар, кайтарып бирелергә тиешле түгел.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләмә “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы тарафыннан раслангannan соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә теркәлгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен тапшыру.

3.1.8. Техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Элек бирелгән әмернамәдә җибәрелгән техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүгә бәйле рәвештә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе яңадан рәсмиләштерелә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яңадан рәсмиләштерү шушы Административ регламентның 8 кушымтасына туры китереп төзелгән, теркәлгән, төзәтелергә тиешле техник хаталарны күрсәтеп, ирекле рәвештә тапшырыла торган гариза нигезендә гамәлгә ашырыла. Гаризага дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак, техник хатасы булган дәүләт экспертизасы бәяләмәләре һәм Мөрәҗәгать итүченең техник заказчы (төзүче) исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документы теркәлә.

3.1.8.1. “ТР ДЭББИ” ДАУ белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы тарафыннан карап тикшерелгәч, башлык дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап әзерләү турындагы резолюциягә имза сала, башкару өчен җаваплы затны билгели.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергәннән соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, башкару өчен җаваплы белгечкә тапшырылган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.1.8.2. Җаваплы белгеч:

дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы боерыгы проектын әзерли;

“ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы боерыгы проектын килештерү өчен “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгына (ул булмаганда, аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар Бүлеккә гаризаны җибәргәннән соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгына килештерү өчен юлланган әмернамә проекты.

3.1.8.3. “ТР ДЭББИ” ДАУ башлыгы (ул булмаганда – аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яңадан рәсмиләштерү турында яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турындагы боерыкны раслый. Имзаланган боерык җаваплы белгечкә

җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура проект раслауга тапшырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яңадан рәсмиләштерү турында яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык.

3.1.8.4. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул ителгән очракта, белгеч, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яки дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып һәм Мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең әзер булуы турында хәбәр итә:

Мөрәҗәгать итүче аны шәхсән алу теләген белдергән булса, үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең датасы һәм вакыты турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар беренче дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүче белән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу ысулын килештерү.

Үзгәрешләр кертүдән баш тарту очрагында Мөрәҗәгать итүчегә язмача җавап бирелә.

3.1.8.5. Мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы төзәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

Җаваплы белгеч, Мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап, бәяләмә яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап тапшыра (җибәрә).

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатасы төзәтелгән, Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.1.9. Дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру.

3.1.9.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә дәүләт экспертизасы эше ачыла. Дәүләт экспертизасы эшләре даими рәвештә саклана торган архив документларына карый. Аларны юкка чыгару, төзәтү һәм (яки) аларда саклана торган документларны алу рөхсәт ителми.

3.1.9.2. Дәүләт экспертизасы эшенә түбәндәгеләр урнаштырыла:

1) Дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза.

2) Шартнамә күчермәсе.

3) Экспертизаны үткәрү өчен шартнамә нигезендә җәлеп ителгән оешмалар һәм (яки) белгечләр тарафыннан чыгарылган нәтиҗәләрне үз эченә алучы документлар.

4) Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

5) Мөрәҗәгать итүченең карточкасы.

6) Дәүләт экспертизасын үткәрүгә бәйле булган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бүтән документлар (документларның күчермәләре).

Проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре, шулай ук шушы Регламентта каралган башка документлар электрон рәвештә тапшырылган булсалар, дәүләт экспертизасы эше электрон рәвештә алып барыла һәм анда дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган барлык документлар урнаштырыла. Электрон рәвештә тапшырылган документларны төзәтү һәм юкка чыгару рөхсәт ителми.

3.1.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару.

3.1.10.1. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлыкның 2007 елның 2 июлендәге “Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләренә карата бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм шушы Реестрда булган белешмәләрне тапшыру тәртибе турында” № 186 боерыгы нигезендә “ТР ДЭББИ” ДАУ Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча бирелгән бәяләмәләр реестрын алып барыла.

Реестрда түбәндәге бүлекләр бар: эшләрне башкаручылар турында идентификация белешмәләре; проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына тапшырылган капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре; төзүче яки заказчы турында идентификация белешмәләре; дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе турында белешмәләр (тискәре һәм уңай бәяләмәләр); бәяләмәнең бирелү датасы һәм аның реквизитлары.

1) “Эшләрне башкаручылар турында идентификация белешмәләре” бүлегенә түбәндәгеләр кертелә:

а) проект документларын әзерләгән һәм (яки) инженерлык тикшеренүләрен башкарган затлар турында идентификация белешмәләре (шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документларның реквизитлары, яшәгән урынының почта адресы; юридик затның тулы аталышы, урнашкан урыны);

б) дәүләт экспертизасын үткәргәндә катнашкан дәүләт экспертлары һәм бәяләмәне раслаган зат турында белешмәләр (дәүләт экспертының фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документларның реквизитлары яки аттестат номеры);

в) дәүләт экспертизасын үткәрү буенча шартнамә нигезендә җәлеп ителгән оешмалар турында идентификация белешмәләре (юридик затның тулы аталышы, урнашкан урыны);

г) дәүләт экспертизасын үткәрү буенча шартнамә реквизитлары;

д) дәүләт экспертизасын үткәрү буенча җәлеп ителгән оешмалар белән шартнамәләрнең реквизитлары.

2). “Проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына тапшырылган капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре” бүлегенә түбәндәгеләр кертелә:

а) проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына тапшырылган капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре: төзелеше (үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше) күздә тотыла торган объектның (объектларның) аталышы, капиталь төзелеш объектының (объектларының) почта (төзелеш) адресы, капиталь төзелеш объектының (объектларының) төп техник-икътисади сыйфатламалары (мәйданы, күләме, озынлыгы, катларының саны, җитештерү куәте, башка сыйфатламалары);

б) дәүләт кадастр исәбенә алынган капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау планлаштырыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;

в) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау планлаштырыла торган җир кишәрлегенең дәүләт төзелеше планы номеры, шулай ук мондый шәһәр төзелеше планын раслый торган актның аталышы һәм реквизитлары;

г) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау планлаштырыла торган җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның аталышы һәм реквизитлары.

3). “Төзүче яки заказчы турында идентификация белешмәләре” бүлегенә төүбәндәгеләр кертелә:

а) төзүче турында идентификация белешмәләре (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклый торган документының реквизитлары, юридик затның тулы аталышы, урнашкан урыны);

б) проект документларын, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен әзерләүче заказчы турында идентификация белешмәләре (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документларның реквизитлары, яшәгән урыны буенча почта адресы; юридик затның тулы аталышы, урнашкан урыны).

4). “Дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе турында белешмәләр” бүлегенә түбәндәгеләр кертелә:

а) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе нәтиҗәсе (уңай; тискәре – инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең норматив таләпләргә җавап бирмәве; тискәре – проект документларындагы техник өлешнең норматив таләпләргә җавап бирмәве; тискәре – сметаның норматив таләпләренә җавап бирмәве; тискәре – проект документларында техник өлешнең һәм сметаның норматив таләпләргә җавап бирмәве);

б) аларга карата дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелгән материаллар турында белешмәләр (инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре; проект документлары һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре);

в) дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә булган нәтиҗәләрне бәхәс кылу турында мәгълүмат (аның нигезендә бирелгән бәяләмә куллану өчен яраклы булмаган актның аталышы һәм реквизитлары).

5). “Бәяләмәнең бирелү датасы һәм аның реквизитлары” бүлегенә түбәндәгеләр кертелә:

а) Реестрдагы дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең теркәлү номеры (алга таба – теркәлү номеры);

б) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган документларны алу датасы;

в) шартнамә нигезендә дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү керткәнне раслый торган документларны Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшыру датасы;

г) Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү (тапшыру) датасы;

д) куллanыла торган типик проект документларына карата уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең реквизитлары (номеры, бирелгән датасы);

е) дәүләт экология экспертизасын үткәрү каралган капиталь төзелеш объектларына карата мондый экспертиза бәяләмәсенең реквизитлары (номеры, бирелү датасы).

“Дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе турындагы белешмәләр” бүлегеннән белешмәләрне кертү дәүләт экспертизасын үткәрү буенча оешма тарафыннан шундый мәгълүмат алынган көнне гамәлгә ашырыла. Калган белешмәләр Реестрга Мөрәҗәгать итүчегә эксперт бәяләмәсен җибәргән (тапшырган) вакыттан башлап өч эш көне дәвамында кертелә.

Кертелгән белешмәләрне юкка чыгару яки төзәтү рөхсәт ителми, аларда техник хаталарны ачыклаган очракта, язуларны төзәтүдән кала.

Мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла торган һәр дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә Реестрны алып бару тәртибе турында нигезләмәгә (Реестрны алып бару тәртибе турында нигезләмәгә карата 2 кушымта) туры китереп билгеләнгән теркәү номерын формалаштыру кагыйдәләре нигезендә Ресстрда дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең теркәлү номеры күрсәтелә.

Реестр электрон рәвештә алып барыла.

“ТР ДЭББИ” ДАУ, югарыда аталган Реестрны алып бару тәртибе турында нигезләмәгә таянып, түбәндәгеләрне тәэмин итә:

белешмәләрне Реестрга үз вакытында кертә;

кызыксынган затларга аларның гарызнамәләре нигезендә Реестрдан өземтәләрне үз вакытында тапшыра;

Реестрда булган мәгълүматны проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисапнамә тапшыру кысаларында Росстройга үз вакытында җибәрә;

кирәк булганда аны яңадан торгызу максаты белән Реестрның мәгълүмат массивының резерв күчермәләрен булдыра;

Реестрдагы мәгълүматларның саклanышын, дөрес булуын, бөтенлеген, файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук аталган мәгълүматларны законсыз файдаланудан яклауны тәэмин итә.

3.1.11. Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү.

Бирелгән бәяләмәләр реестрында булган белешмәләр теләсә нинди кызыксынган затлар алар белән таныша алсын өчен ачык булып санала, федераль законнарда каралган очраклардан тыш.

Реестрдагы белешмәләр физик һәм юридик затларга, дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның структур бүлекчәләренә, җирле үзидарә органнарына, алардан язмача гарызнамә алынгач 10 (ун) көн дәвамында, түләү алмыйча тапшырыла.

Гарызнамә "ТР ДЭББИ" ДАУ теләсә нинди ысул белән (кәгазьдә яки электрон рәвештә) шушы Административ регламентның 1.3 бүлегендә күрсәтелгән почта яки электрон адресларга җибәрелә һәм Мөрәҗәгать итүче турындагы идентификация белешмәләрен (физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, шәхесен таныклый торган документларның реквизитларын; яшәгән урыны буенча почта адресын; юридик затның тулы аталышын, урнашкан урынын; электрон адресын) үз эченә алырга, шулай ук төзелеше, үзгәртеп корылышы һәм капиталь ремонты башкарыла торган яки төгәлләнгән (туктатылган) билгеле бер объектка карата мәгълүмат җиткерүне күздә тотарга тиеш.

Мәгълүмат Нигезләмәгә карата 2 кушымтага туры китереп, Реестрдан өземтәләр нигезендә тапшырыла (гарызнамәдә күрсәтелгән теләсә нинди рәвештә).

Реестрдан алынган мәгълүматта, документларның реквизитлары турындагы белешмәләрдән кала, проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы физик затның шәхесен таныклый торган белешмәләр булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча оешма дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы гарызнамәсе буенча Реестрда булган башка белешмәләрне җиткерергә мөмкин. Бу вакытта белешмәләрне җиткерү вакыты озынайтылырга мөмкин, ләкин ун көннән дә артыграк түгел.

Сорала торган белешмәләр булмаганда яки аларны тапшыру мөмкин булмаганда Мөрәҗәгать итүчегә бу хакта язмача рәвештә гарызнамәне алганнан соң ун көн дәвамында хәбәр ителә.

Бирелгән бәяләмәләрнең реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирми торган гарызнамә алынган очракта, "ТР ДЭББИ" ДАУ ун көн дәвамында, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, белешмәләрне тапшырудан баш тарту турында хат җибәрә (гарызнамәдә күрсәтелгән теләсә нинди рәвештә).

3.12. Дәүләт хезмәтен яңадан күрсәтү, бәяләмә дубликатын бирү.

Дәүләт экспертизасын яңадан үткәрү Нигезләмәнең 44, 45 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла:

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән очракларда;

әгәр дә беренче (аннан алдагы) дәүләт экспертизасын үткәргәннән соң Россия Федерациясе законнарына дәүләт экспертизасы нәтиҗәсенә йогынты ясый ала торган үзгәрешләр кертелсә, тапшырылган инженерлык тикшеренүләре тулысынча эксперт бәяләмәсенә дучар ителергә мөмкин.

Яңадан дәүләт экспертизасы шушы Регламентта беренче дәүләт экспертизасын үткәрү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен югалткан очракта мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасын үткәрүче оешмадан әлеге бәяләмәнең дубликатын алырга хокуклы. Дубликат язмача мөрәҗәгать алынган датадан соң 10 көн эчендә түләүсез бирелә.

3.13. Күпвазифалы үзәкләрдә, шулай ук читтән торып эшләү урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. “ТР ДЭББИ” ДАУ вазифаи затлары тарафыннан шушы Административ регламентның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләрне билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылышын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольлектә тоту тиешле административ процедураны башкарган өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек “ТР ДЭББИ” ДАУ вазифаи затлары тарафыннан шушы Административ регламентның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләрне билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләренең үтәлешенә һәм башкарылышына карата тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын контрольлектә тоту тикшерүләр үткәрүне, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклауны һәм юкка чыгаруны, карарлар кабул итүне һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең “ТР ДЭББИ” ДАУ вазифаи затларының караларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрдән гыйбарәт булган мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын тикшерү “ТР ДЭББИ” ДАУ актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (“ТР ДЭББИ” ДАУ ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын карата планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) шушы Административ регламентның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә

карата таләпләрне билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләрен бозу буенча элек ачыкланган очракларның юкка чыгарылуын тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик затларның һәм юридик затларның дәүләт хезмәтен күрсәткәндә катнашучы “ТР ДЭББИ” ДАУ вазифаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турындагы мөрәҗәгатьләре нигезендә.

4.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

4.7. Үткәрелгән тикшерүләр буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча җаваплы булган, гаепле дип танылган затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә “ТР ДЭББИ” ДАУ эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук аның вазифаи затларының, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәрге тәртиптә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы “ТР ДЭББИ” ДАУ хезмәткәрләренең гамәлләрен (гамәл кылмавын) “ТР ДЭББИ” ДАУ җитәкчесенә шикаять итәргә хокуклы.

“ТР ДЭББИ” ДАУ җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга (аның гамәлләренә) карата шикаятьләр Министрлыкка, җитәкчелек итүче министр урынбасары яки министр исеменә тапшырыла, министр урынбасары (министр) тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять кылынырга мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белдерергә хокуклы:

дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы

норматив-хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәткән органның, органдагы дәүләт хезмәтен күрсәткән вазифаи затның дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тапшырылган нәтиҗәсендә җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша җибәрелергә, күпвазифалы үзәк аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша тапшырылырга, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазифаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуын яки мондый төзәтмәләрнң билгеләнгән вакыты бозылуны шикаять кылганда – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның аталышы, карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителә торган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазифаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, аның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче шулар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, аның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган дәлилләр.

5.6. Шикаятькә анда бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге күрсәтелә.

5.7. Шикаять шәхсән яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазифаи зат, орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән язу хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Проект документларына һәм (яки)
инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен
күрсәтүнең административ регламентына
карата 1 кушымта

Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча
блок-схема

Дәүләт экспертизасын үткәрүгә гаризаны һәм Теркәү өчен документлар исемлеге (3 кушымта) нигезендә документларны кабул итү һәм теркәү.
Башкаручы – Техник хезмәт.
Үтәү чоры – 1көн.

↓

ВЭХС ярдәмендә электрон рәвештә белешмәләр тапшыру турында гарызнамәләрне җибәрү һәм җавапларны алу.
Башкаручы – Техник хезмәт.
Үтәү чоры – 5 эш көне дәвамында.

↓

Шушы Регламентка карата 3 кушымтага туры китереп, кирәкле документларның булу-булмавын тикшерү.
Башкаручы – Техник хезмәт.
Үтәү чоры – 3 көн.

→ Документларны кабул итүдән баш тарту, Мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кайтарып бирү

↓

“ТР ДЭББИ” ДАУ белән Мөрәҗәгать итүче арасында дәүләт экспертизасы бәясен билгеләп, хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә төзү, шартнамәне Мөрәҗәгать итүчегә җибәрү
Башкаручы – Техник хезмәт.
Үтәү чоры – 3 көн.

↓

Проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү.
Башкаручы - “ТР ДЭББИ” ДАУ экспертиза хезмәте.
30 эш көненнән артмый.

↓

Уңай (тискәре) дәүләт экспертизасы бәяләмәсен төзү һәм тапшыру.
Башкаручы: әйдәп баручы эксперт, техник хезмәт. Үтәү чоры Хезмәтләр күрсәтү шартнамәсенең гомуми вакытына керә.

↓

Дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру. Башкаручы – техник хезмәт.
Башкару чоры – Мөрәҗәгать итүчегә эксперт бәяләмәсен биргәннән соң 5 көн

↓

Бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару.
Башкаручы – техник хезмәт. Үтәү чоры – заказчыга эксперт бәяләмәсен тапшырганнан соң 3 көн

↓

Физик затларның һәм юридик затларның гарызнамәләре буенча реестрда булган мәгълүматларны житкерү. Башкаручы – техник хезмәт.
Үтәү чоры – 10 көн.

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 2 кушымта

проект

**Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча**
**№ ШАРТНАМӘ РӘВЕШЕ**

Казан ш. "_____" _____________ 201__ ел

"Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе" дәүләт автоном учреждениесе, алга таба "Башкаручы" дип исемләнә, ____________________________________________________________нигезендә ____________________________________________________________________ исеменнән гамәл кылучы, бер яктан, һәм______ ____________________, алга таба "Заказчы" дип исемләнә, икенче яктан, шушы шартнамәне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

**1. Шартнамәнең предметы**

1.1. Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча әлеге шартнамә (алга таба – "Шартнамә") шартлары буенча Башкаручы Заказчының гаризасы буенча түбәндәге хезмәтне күрсәтү: ______________________________________________________________ капиталь төзелеш объектының _____________________________________________________________ дәүләт экспертизасын үткәрү, ә Заказчы шушы хезмәт өчен түләү һәм дәүләт экспертизасын үткәрү нәтиҗәләрен кабул итеп алу йөкләмәсен ала.

1.2. Проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы № 145 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 16 февралендәге "Проект документларындагы бүлекләрнең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында" № 87 карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрүне оештыру турында нигезләмәдә (алга таба – "Нигезләмә") һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы башка норматив-хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.3. Дәүләт экспертизасын үткәрү нәтиҗәсе булып Башкаручының Заказчы тапшырган проект документларының техник регламентларның таләпләренә һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә, проект документларының бүлекләре эчтәлекләре таләпләренә җавап бирүе турында (уңай бәяләмә) яки җавап бирмәве турында (тискәре бәяләмә), шулай ук, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясалган очракта, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең техник регламентларның таләпләренә җавап бирүе турында бәяләмәсе тора.

1.4. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе Мөрәҗәгать итүченең кулына тапшырыла яисә заказлы хат юллау ысулы белән җибәрелә. Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе 4 (дүрт) нөсхәдә тапшырыла. Тискәре бәяләмә 1 (бер) нөсхәдә тапшырыла.

**2. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәт өчен түләү**
**һәм аны хисаплау тәртибе**

2.1. Экспертизаның бәясе Нигезләмә нигезендә ачыклана.

2.2. Шушы Шартнамәнең 1.1 пункты буенча, дәүләт экспертизасын үткәргән өчен Заказчы Башкаручыга аның бәясен түләү күләменә (Шартнамәгә карата 1 кушымта) туры китереп түли, ул ________________________ (сумма хәрефләр белән языла) сум тәшкил итә, шул исәптән 18% ставка буенча НДС - ____________________сум.

Карала торган проект документлары буенча дәүләт экспертизасын үткәргәндә проект документларының күләме, инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре артканда һәм (яки) проект-тикшеренү эшләренең бәяләре үзгәргәндә, Шартнамә буенча экспертизаның бәясе тәгаенләнергә тиеш.

2.3. Хезмәт өчен дәүләт экспертизасының нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә түләнә.

2.4. Заказчы шушы Шартнамә имзаланганнан соң 5 (биш) эш көне дәвамында шушы Шартнамәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт экспертизасы бәясеннән 100% дәрәҗәсендә Башкаручының хисап счетына аванс түләве тәртибендә счет нигезендә түләү түли.

2.5. Счетны түләү көне булып акчаларның Башкаручының хисап счетына килгән, банктан алынган өземтәдә расланган көне санала.

2.6. Хезмәтне күрсәтә алмау мөмкинлеге Бер як та җаваплы булмаган шартлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән очракта, Заказчы Башкаручыга аның тарафыннан фактта тотылган чыгымнарны түли, әгәр дә законда башкача каралмаса.

2.7. Яңадан дәүләт экспертизасын үткәргән өчен беренче мәртәбә дәүләт экспертизасына түләнгәннең 30 проценты күләмендә түләү алына. Әгәр дә капиталь торак төзелеше объектларына карата яңадан дәүләт экспертизасыа үткәрү документлары тискәре бәяләмәне алганнан соң 14 көн эчендә тапшырылган булсалар, яңадан экспертиза үткәргән өчен түләү алынмый.

2.8. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе буенча акчаларны өченче зат тарафыннан Башкаручының хисап счетына күчерү юлы белән дә түләнергә мөмкин.

**3. Дәүләт экспертизасын үткәрү чоры**

3.1. Шартнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән түләү өлеше Башкаручының хисап счетына күчкәннән соң Башкаручы 30 эш көне дәвамында тапшырылган проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрә һәм бәяләмә әзерли.

3.2. Башкаручы экспертизага шартнамә мөнәсәбәтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән һәм Заказчы тарафыннан Нигезләмә (28 пункты) һәм Шартнамә (2.5 пункты) нигезендә хезмәтнең тулысынча бәясе түләнгән көннән соң килүче көннән башлап керешә.

3.3. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәтнең күрсәтелүе Яклар тарафыннан Башкаручы раслаган (Шартнамәгә карата 2 кушымта) рәвештә дәүләт экспретизасы буенча күрсәтелгән Хезмәтләрне кабул итү актына (алга таба “Акт”) имза салып раслана.

Әгәр дә Мөрәҗәгать итүче Актка имза салудан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы хезмәт күрсәткән көннән соң 5 (биш) календарь көне дәвамында язмача рәвештә баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә дәлилле баш тарту Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән чорларда тапшырылмаган икән, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә, нинди дә булса шелтәләрсез башкарылган дип санала. Дәлилле баш тартуда шушы Шартнамәдә каралган йөкләмәләрнең чикләреннән узмый торган кисәтүләр булырга тиеш.

3.4. Хезмәтләр күрсәтелеп беткәч Башкаручы тарафыннан счет-фактура бирелә.

**4. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Дәүләт экспертизасын үткәрү барышы турында мәгълүмат алырга һәм Башкаручыга аңлатмалар, өстәмә белешмәләр һәм документлар тапшырырга.

4.1.2. Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документларына үзгәрешләрне оператив кертергә.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән Шартнамәгә имза салырга һәм аны Башкаручыга кайтарырга, шушы Шартнамә шартларында хезмәт өчен түләргә.

Күрсәтелгән хезмәтнең нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, хезмәтне Акт буенча кабул итеп алырга, Актка имза салырга һәм аны уңай яки тискәре бәяләмәне рәсмиләштергән датадан соң 5 (биш) календарь көне эчендә Башкаручыга кайтарып бирергә, бәяләмәне рәсмиләштергән датадан соң 14 календарь көне эчендә счет-фактураны алырга.

4.2.2. Башкаручыга дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле булган проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен кәгазьдә һәм электрон рәвештә тапшырырга. Заказчы тапшырылган документларның сыйфаты һәм дөреслеге өчен җаваплы була.

4.2.3. Башкаручының таләбе буенча кабул ителгән проект карарларын нигезләү өчен өстәмә материалларны, проект документларында файдаланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең хисапнамәләрен, шулай ук инженерлык тикшеренүләре материалларын кәгазьдә һәм электрон рәвештә тиешле гарызнамәне Башкаручыдан алганнан соң биш көнлек чорда тапшырырга.

4.2.4. Хезмәт өчен шушы Шартнамәнең 2 өлешендә каралган тәртиптә, күләмнәрдә һәм вакытларда түләргә.

4.2.5. Бәяләмәне алганнан соң 1 (бер) айдан да соңга калмыйча Башкаручыдан дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган документларны алырга.

4.2.6. Нәтиҗәләре нинди булуга бәйсез рәвештә (уңай яки тискәре) бәяләмәне алырга һәм Актка имза салырга.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Шушы Шартнамә шартлары буенча хезмәтләр өчен түләү таләп итәргә.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсына торган оешмалардан дәүләт экспертизасын үткәрү һәм Башкаручыга йөкләнгән йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле материалларны соратырга.

4.3.3. Шартнамә нигезендә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча башка дәүләт һәм (яки) дәүләткә карамаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итәргә.

4.3.4. Заказчыдан проект карарларын нигезләү буенча өстәмә материалларны, проект документларында файдаланыла торган конструктив һәм технологик караларның хисапнамәләрен, шулай ук инженерлык тикшеренүләре материалларын соратып алырга.

4.3.5. Заказчының үзенең шушы Шартнамә буенча бурычларын үтәмәве, асылда, 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән техник документларны тапшырмавы, 2.2, 2.4 пунктларында күрсәтелгән түләүне түләмәве Башкаручы тарафыннан Шартнамәне үтәргә каршылык тудырса, шулай ук аталган бурычларның билгеләнгән чорда үтәлмәвен ачыктан-ачык дәлилли торган шартлар булганда. хезмәтне күрсәтүгә керешмәскә, ә күрсәтелә башлаган хезмәтне туктатырга.

4.4. Башкаручының бурычлары:

4.4.1. Тапшырылган документларның сакланышын тәэмин итү, шулай ук Башкаручыга дәүләт экспертизасын үткәрүгә бәйле рәвештә билгеле белган проект карарларын һәм башка конфеденциаль мәгълүматларны өченче затларга таратмау буенча чаралар күрергә.

4.4.2. Проект документларына дәүләт экспертизасын Шартнамәдә һәм норматив-хокукый актларда билгеләнгән чорларда үткәрергә.

4.4.3. Шартнамәне рәсмиләштергәч, экспертизаны үткәргәч, экспертиза өчен тулысынча түләнгәч һәм Актка имзалар салынгач, Заказчыга шушы Шартнамә шартларында уңай яки тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсен, шулай ук Шартнамәнең 5.2 пунктында каралган тәртиптә тапшырылган проект документларын бирергә.

4.4.4. Эксперт бәяләмәсендә техник хата ачыкланган очракта 5 көн эчендә әлеге хатаны төзәтергә һәм Заказчыга төзәтелгән бәяләмәне тапшырырга.

**5. Дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кабул ителгән документларны кайтарып бирү тәртибе һәм вакытлары**

5.1. Документларны карамыйча кайтарып бирү тәртибе һәм вакытлары һәм документларны кабул итүдән баш тарту Нигезләмә нигезендә (Нигезләмәнең 22-25 пунктлары) регламентлана.

5.2. Проект документлары, проектлауга карата биремнең күчермәсе, инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре һәм инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата биремнең күчермәсе дәүләт экспертизасын үткәргәннән соң, дәүләт экспертизасы бәяләмәсен тапшырган датадан бер айдан соңга калмаган вакыт эчендә Заказчыга кайтарып бирелергә тиеш.

5.3. Заказчы дәүләт экспертизасына тапшырган документларны алудан баш тарткан очракта яки Шартнамәдә күрсәтелгән вакыт узганнан соң Башкаручы, Заказчыга билгеле бер вакытын күрсәтеп, документларны алу кирәклеге турында белдерүнамә җибәрә. Белдерүнамәдә күрсәтелгән чор узганнан соң 1 (бер) ай узгач Башкаручы Заказчы тарафыннан тапшырылган документлар тупланмасының сакланышы өчен җаваплы булмый, документлар юкка чыгарылырга тиеш.

**6. Шартнамәне тарткату тәртибе**

6.1. Бу Шартнамә Заказчының гаризасы буенча вакытыннан алда (экспертиза үткәрелгән чорда) таркатылырга мөмкин, шул ук вакытта гариза кергән чорга карап тикшерелгән документларның экспертизасы бәясе алына. Заказчы Башкаручыга Шартнамәне туктатуга бәйле чыгымнарны, барлык эш өчен билгеләнгән түләү күләме белән башкарылган эш өчен түләнгән түләү өлешенең аермасы чикләрендә түләргә тиеш.

6.2. Заказчы тарафыннан Шартнамә шартлары җитди бозылган очракта. Шартнамә Башкаручы инициативасы белән таркатыла, ә атап әйткәндә, түбәндәге очракларда:

6.2.1. Заказчы шушы Шартнамәдә һәм федераль һәм республика законнарында каралган документларны һәм проект документларын тапшырмаганда;

6.2.2. Заказчы түләүне 30 (утыз) календарь көненнән артык вакытка кичектергәндә;

6.2.3. Заказчы Башкаручыга белә торып дөрес булмаган һәм/яки тулы булмаган мәгълүматларны тапшырганда.

6.2.4. Экспертиза үткәрү барышында проект документларында һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрендә ачыкланган җитешсезлекләрне Заказчы Башкаручы тарафыннан билгеләнгән чорда бетермәгәндә:

6.2.4.1. Дәүләт экспертизасын үткәргәндә проект документларында проект документларының техник регламентларның һәм башка норматив документларның таләпләренә җавап бирүе яки җавап бирмәве турында йомгак ясарга мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, хисапнамәләрнең, сызымнарның, схемаларның h.б. булмавы (тулы булмавы)) ачыкланганда, Башкаручы Заказчыга кичекмәстән ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр итә һәм кирәк булганда аларны юкка чыгару вакытын билгели – Башкаручы тарафыннан кисәтүләр теркәлгән көннән соң 10 (ун) календарь көне.

6.2.4.2. Әгәр дә ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләт экспертизасы барышында бетерергә мөмкин булмаса яки Заказчы аларны билгеләнгән чорда бетермәсә, Башкаручы экспертизаны алга таба үткәрүдән баш тартырга һәм Шартнамәне вакытыннан алда тарткату мәсьәләсен күтәрергә хокуклы, бу хакта ул Заказчыга Шартнамәнең 6.2.4.1 пунктында билгеләнгән чор узганнан соң өч көнлек чорда, кабул ителгән карарның нигезләрен күрсәтеп, язмача хәбәр итә һәм проект документларын Заказчыга кайтарып бирә.

6.3. Башкаручыга яки Заказчыга таркату турында рәсми рәвештә белдергәннән соң, белдерү чорыннан соң 1 (бер) айдан соңга калмыйча, Шартнамә таркатылган булып санала.

**7. Махсус шартлар**

7.1. Проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре федераль һәм республика законнары таләпләреннән тайпылып башкарылган очракта, ә аның күләме һәм эчтәлеге проект карарын нигезләү өчен җитәрлек булмаса, Башкаручы алдан кисәтүләр ясамыйча тискәре бәяләмә бирергә хокуклы.

7.2. Заказчы шушы Шартнаменең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Шартнамә Заказчы тарафыннан Шартнамәнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшырмау датасы белән документларны тапшыру датасы арасындагы көннәр саныннан артмаган чорга озынайтыла.

7.3. Билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән эксперт бәяләмәсен Башкаручы Заказчыга түбәндәгеләр булганда тапшырырга хокуклы:

- вәкилдә шушы Шартнамә буенча эксперт бәяләмәсен алуга карата ышанычнамә һәм аның шәхесен таныклый торган документы (паспорты);
- эксперт бәяләмәсен алган вакытка Закачы имзалаган Акт.

**8. Шартнамәдән килеп чыга торган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы, форс-мажор**

8.1. Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы булалар.

8.2. Әгәр дә йөкләмәләрне үтәмәү өчен күрелмәгән һәм юкка чыгарып булмый торган гадәттән тыш сыйфатлы вакыйгалар аркасында барлыкка килгән, җиңеп булмый торган көч яки башка якның гаебе сәбәпче булса, шушы Шартнамә буенча йөкләмәләрне өлешчә яки тулысынча үтәмәгән өчен Яклар җаваплылыктан азат ителә.

8.3. Шартнамә буенча ризасызлыклар һәм бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару юлы белән, ә ризалыкка ирешмәгән очракта Татарстан Республикасының Арбитраж судында хәл ителә.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Бу Шартнамә Заказчы документларны тулы күләмдә тапшырган, хезмәт өчен түләгән вакыттан башлап үз көченә керә һәм Яклар өчен мәҗбүри була һәм Яклар тарафыннан үзләренең йөкләмәләре тулысынча үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

9.2. Шушы Шартнамәгә кертелә торган үзгәрешләр аңа карата өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

9.3. Хәзергесе белән Яклар үзләренең, аларның аффилир затларының, хезмәткәрләренең яки арадашчыларының шушы Шартнамәне имзалаганчыга кадәр, шулай ук шушы Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәү вакытында турыдан-туры яки кыеклатып теләсә нинди затларга нинди дә булса хокуксыз өстенлекләр алу яки башка төрле хокуксыз максатларга ирешү максатларында, шул исәптән әлеге Шартнамәне имзалау һәм башка максатларда әлеге затларның гамәлләренә яки карарларына йогынты ясау өчен нинди дә булса акчаларны яки кыйммәтләрне түләмәүләрен/түләмәячәкләрен, түләүне тәкъдим итмәүләрен/тәкъдим итмәячәкләрен һәм түләү өчен рөхсәт бирмәгәнлекләрен/рөхсәт бирмәячәкләрен, шулай ук ришвәт бирү яки алу, коммерциячел сатып алу кебек квалификацияләнә торган гамәлләрне, шулай ук Россия Федерациясенең җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) карата көрәш турындагы һәм коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары таләпләрен боза торган гамәлләрне башкармауларын раслыйлар.

Югарыда санап үтелгән хәлләрнең берсе булса да барлыкка килгән очракта, әлеге нигезләмәләрнең бозылуы турында белгән зат бу хакта Якларның җитәкчелегенә кичекмәстән хәбәр итү бурычын үз өстенә ала.

9.4. Бу Шартнамә бер үк төрле юридик көчкә ия булган, һәр Як өчен берәр нөсхә буенча 2 (ике) нөсхәдә төзелде.

9.5. Бу Шартнамәгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора:
- түләү күләме (Шартнамәгә карата 1 кушымта) __ биттә, 1 биттә Акт (Шартнамәгә карата 2 кушымта).

9.6. Яклар 10 көнлек чорда бер-берсенә үзләренең адреслары һәм түләү реквизитлары үзгәрү турында язмача хәбәр итәргә бурычлы.

**10. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары:**

**ЗАКАЗЧЫ:**

_____________________

“Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе
Юридик (фактик) адресы:
420073, Казан ш., Шуртыгин ур., 22
ИНН 1654017928/ КПП 166001001
Казан ш. “Ак Барс” банк” ААҖ
Алучы: ТР Финанс министрлыгы (“Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе
л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)
р/с 40601810700023000003
КПС 71300000000000000130
ОКТМО 92701000
БИК 049205805
К/с 30101810000000000805

**_______________№_____________ шартнамәгә карата 1 кушымта**

**Торак булмаган капиталь төзелеш объектларының проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү бәясен ХИСАПЛАУ**

Объект:

Заказчы:

Экспертизаны үткәрү хакы агымдагы бәяләрдә:

$$С_{Э\ ТЕК} = (Спр \times Ki + Сиз \times Ki) \times П \times НДС$$

**$С_{Э\ ТЕК}$ = (сум,**

биредә:

Спр = - 2001 ел бәяләрендә проект документларын әзерләү хакы.

Сиз = - 2001 ел бәяләрендә тикшеренү эшләренең хакы.

Ki = - 01.01.01 белән чагыштырмача 01.01.15 карата инфляция индексы

П = - 05.03.07 № 145 РФ Хөкүмәте карары буенча 2001 елдагы бәяләр дәрәҗәсендә дәүләт экспертизасына тапшырылган проект һәм (яки) тикшеренү эшләренең суммар хакыннан бер өлеше

**Моннан тыш, 18% НДС - сум.**
**Башкарылган эшләрнең хакы – сум.**

**Хисап эшләрен башкарды** ________________________________

**______________№____________ шартнамәгә карата 1 кушымта**

“Татарстан Республикасының Төзелеш
һәм архитектура буенча дәүләт
экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе”
дәүләт автоном учреждениесе
Юридик (фактик) адресы:
420073, Казан ш., Шуртыгин ур., 22
ИНН 1654017928/ КПП 166001001
Казан ш. “Ак Барс” банк” ААҖ
Алучы: ТР Финанс министрлыгы
(“Татарстан Республикасының Төзелеш
һәм архитектура буенча дәүләт
экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе”
дәүләт автоном учреждениесе
л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)
р/с 40601810700023000003
КПС 71300000000000000130
ОКТМО 92701000
БИК 049205805
К/с 30101810000000000805

**Дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү**
**АКТы**

Башкаручы – “Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе, _________________________________ исеменнән,___________________________________ нигезендә гамәл кылучы тапшыра, ә Заказчы – _______________________, _____________ исеменнән, күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итеп ала.

Хезмәтләр __________________№______ шартнамә нигезендә күрсәтелде.

Исәп-хисап бәясе –

Моннан тыш, НДС 18% -

Җәмгысе –

Сыйфаты шартнамә шартларына җавап бирә. ________№____ шартнамә буенча йөкләмәләр Башкаручы тарафыннан тулы күләмдә һәм тиешле сыйфатта башкарылды, Заказчының дәгъвалары юк. Актка дәүләт экспертизасының бәяләмәсе теркәлә:

№ ел.

| | |
|---|---|
| **Заказчы:** | **Башкаручы:** |
| _____________ | ______________ |
| «_______»_________ел. | «______»_________ел. |

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 3 кушымта

**Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча тапшырыла торган документлар исемлеге:**

1. Бер үк вакытта проект документларына һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча түбәндәгеләр тапшырыла:

а) дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

эшләрне башкаручылар – проект документларын әзерләүче һәм инженерлык тикшеренүләрен башкаручы затларның идентификация белешмәләре (шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклый торган документының реквизитлары, юридик затның тулы аталышы, урнашкан урыны);

проект документлары һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына тапшырылган капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре: төзелеше (үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше) күздә тотыла торган объектның (объектларның) аталышы, капиталь төзелеш объектының (объектларының) почта (төзелеш) адресы, капиталь төзелеш объектының (объектларының) төп техник-икътисади сыйфатламалары (мәйданы, күләме, озынлыгы, катларының саны, җитештерү куәте, башка сыйфатламалары);

мөрәҗәгать итүче турында идентификация белешмәләре (төзүче (техник заказчы) – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклый торган документының реквизитлары, яшәгән урыны буенча почта адресы, юридик затның тулы аталышы, төзүче – юридик затның урнашкан урыны, ә әгәр дә төзүче (техник заказчы) һәм мөрәҗәгать итүче бер үк зат булмаганда, – шулай ук мөрәҗәгать итүчегә карата да аталган белешмәләр);

г) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән проект документларының бүлекләрендәге составларына һәм эчтәлекләренә карата) нигезендә капиталь төзелеш объектының проект документлары;

д) проектлауга карата бирем (яки аның күчермәсе, – документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә кәгазьдә тапшыру Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителсә);

е) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән аталган нәтиҗәләрнең составына карата) нигезендә инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре;

ж) инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата бирем (яки аның күчермәсе, – документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә кәгазьдә тапшыру Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителсә);

з) әгәр дә дәүләт экспертизасын үткәрү өчен төзелеше яки үзгәртеп корылышы Россия Федерациясенең махсус икътисад зонасында, Россия Федерациясенең континенталь шельфында, эчке диңгез суларында яки Россия Федерациясенең территориаль диңгезендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата эшләнгән проект документлары, шулай ук I-V классы куркыныч калдыкларын урнаштыруга һәм йогышсызландыруга бәйле объектларга, су объектларындагы ясалма җир кишәрлекләренә карата эшләнгән проект документлары тапшырылган очракта (мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасына 1995 елның 23 ноябрендәге "Экология экспертизасы турында" № 174-ФЗ Федераль законның 11 статьясының 7.1 пунктчасында һәм 12 статьясының 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата эшләнгән проект документларын тапшырган очраклардан кала) уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе;

дәүләт катнашында зур инвестиция проектына халыкка ачык технологик аудит үткәрү турында уңай җыелма бәяләмә күчермәсе (әгәр дә халыкка ачык технологик һәм бәя аудитын үткәрү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 30 апрелендәге "Дәүләт катнашында зур инвестиция проектына халыкка ачык технологик аудит үткәрү турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" № 382 карары белән расланган Дәүләт катнашында зур инвестиция проектына халыкка ачык технологик аудит үткәрү нигезләмә нигезендә мәҗбүри булса);

и) Мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документлар (мөрәҗәгать итүче техник заказчы һәм (яки) төзүче булмаган очракта), аларда дәүләт экспертизасын үткәрү турында шартнамә төзү, үзгәртү, башкару, тарткату буенча вәкаләтләр махсус сөйләшенгән булырга тиеш (алга таба – шартнамә);

к) эшләрне башкаручыны проект документларын һәм (яки) инженерлык тикшеренүләрен әзерләү буенча тиешле эш төрләренә кертү буенча үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, башкарылган эшләрне кабул итү актын имзалаган датага гамәлдә булган таныклыклар, Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу мәҗбүри булган очракта, һәм башкарылган эшләрне кабул итү турында акт (яки аларның күчермәләре, – документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә кәгазьдә тапшыру рөхсәт ителсә);

л) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең индивидуаль смета нормативларын эшләү һәм куллану турындагы карары хакында белешмәләр (мондый карар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 16 февралендәге "Проект документларындагы бүлекләрнең составы һәм аларның эчтәлекләренә карата таләпләр турында" № 87 карары белән расланган Проект документларындагы

бүлекләрнең составы һәм аларның эчтәлекләренә карата таләпләр турында нигезләмәнең 30 пункты нигезендә кабул ителгән очракта).

2. Проект документларын дәүләт экспертизасына җибәргәнчегә кадәр инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча Нигезләмәнең 13 пунктындагы “а” һәм “е”-“к” пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырыла.

3. Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән очракларда инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча Нигезләмәнең 1 пунктының “а” һәм “е”-“и” пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырыла, шулай ук:

а) тышкы инженерлык челтәрләре һәм фундаментларның конструктив чишелешләре буенча проект документлары;

б) теләсә нинди затка бирелгән, кулланыла торган проект документларына (модификацияләнгән типик проект документларына) карата уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;

в) төзүченең (техник заказчының) аның буенча махсус хокук башка затныкы булган типик проект документларыннан файдалану хокукынраслый торган документ (махсус хокукны читләштерү турында шартнамә, лицензия шартнамәсе, сублицензияле шартнамә һәм шуңа охшаш документлар);

г) типик проект документларын яңадан файдалану планлаштырыла торган климатка бәйле һәм башка шартларның аның беренче мәртәбә эшләнгән шартларына туры килүен раслый торган документлар. Аталган документның рәвеше Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана;

д) әгәр дә типик документларны кулланганда тышкы инженерлык челтәрләре һәм фундаментларның конструктив чишелешләре буенча проект документларын әзерләү таләп ителсә, – үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән, эшләрне башкаручыны проект документларын һәм (яки) инженерлык тикшеренүләрен әзерләү буенча тиешле эш төрләренә кертү турында, башкарылган эшләрне кабул итү актын имзалаган датага гамәлдә булган таныклыклар, Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу мәҗбүри булган очракта, һәм башкарылган эшләрне кабул итү турында акт (яки аларның күчермәләре, – документларны кәгазьдә тапшырган очракта, әгәр дә Россия Федерациясе законнары нигезендә кәгазьдә тапшыру рөхсәт ителсә).

4. Проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң мондый проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү буенча Кушымтаның 1 пунктында күрсәтелгән документлар (инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата биремнең күчермәсеннән, шулай ук үзеннән-үзе җайга салынулы оешма тарафыннан бирелгән башкаручыны тиешле эш төрләренә кертү турында таныклыкның таныкланган күчермәсеннән кала) һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе

тапшырыла, шул ук вакытта инженерлык тикшеренүләренең нәтиҗәләре яңадан тапшырылмый.

5. Дәүләт экспертизасын үткәрүче оешма мөрәҗәгать итүчедән проект документларында кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең хисапнамәләрен, инженерлык тикшереүләре материалларын өстәмә рәвештә тапшыруны таләп итәргә хокуклы.

6. Шушы Кушымтаның 1-4 пунктларында күрсәтелгән документларны электрон рәвештә тапшыру, шул исәптән, “Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып башкарыла. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы “Проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында” № 145 карарының 2 пунктындагы “к” һәм “л” пунктчаларында каралган чорлар килеп җиткәнчегә кадәр, әгәр дә документлар кәгазьдә тапшырыла икән, дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы шартнамәдә проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең шулай ук электрон рәвештә тапшырылуы каралырга мөмкин.

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 4 кушымта

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча гариза рәвеше

**Оешманың рәсми бланкында**
*(ирекле рәвештә тутырыла)*

---

"ТР ДЭББИ" ДАУ "Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе" дәүләт автоном учреждениесе башлыгы М.Х.Салиховка

Чыгу №____ ___________ ел.

Хөрмәтле Мәҗит Хажип улы!

Объектның (проектлау биремено һәм проект документларына туры китереп объектның аталышы) проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрүне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| Оешманың җитәкчесе | ___________________ | ФИА |
| *(вазифасы)* | *(имзасы)* | *(аңлатмасы)* |

Җаваплы башкаручының ФИА
Тел.

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 5 кушымта

**Мөрәҗәгать итүченең дәүләт экспертизасын үткәрү буенча кирәкле булган, проектка карата төп белешмәләр карточкасы**

**Объектның аталышы**

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(урнашкан урыны, адресы)

______________________________________________

______________________________________________

техник-икътисади сыйфатламалары (мәйданы, күләме, озынлыгы, катлар саны, житештерү куәте)

**Мөрәҗәгать итүче**

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(тулы аталышы, адресы)

______________________________________________тел/факс____________

(житәкчесенең Ф.И.А.)

______________________________________________тел/факс____________

( Мөрәҗәгать итүчедән жав. Башкаручының Ф.И.А.) E-mail ______________________

(мәгълүмат алу өчен)

**Төзүче**______________________________________

______________________________________________

______________________________________________

(тулы аталышы, адресы)

______________________________________________тел/факс____________

(житәкчесенең Ф.И.А.)

**Техник заказчы**______________________________

______________________________________________

(оешманың тулы аталышы)

______________________________________________

______________________________________________тел/факс____________

(житәкчесенең Ф.И.А.)

**Генпроектлаучы**

______________________________________________

______________________________________________

(оешманың тулы аталышы, адресы)

______________________________________________

________________________________________________________тел/факс___________
(җитәкчесенең Ф.И.А.)

**ГИП** ____________________________________________________
тел/факс_________________

(Ф.И.А.)

**Инженерлык тикшеренүләрен башкарган оешманың аталышы:**
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(оешманың тулы аталышы, адресы)
___________________________________________________________
тел/факс___________________
(җитәкчесенең Ф.И.А.)
**Инженерлык тикшеренүләрен эшләү елы**_______________________________________

**Инвестор**
______________________________________________________________________________

**Финанслау чыганагы – шәхси, төбәк бюджеты, федераль бюджет, инвестор акчалары һ.б.**___________________ _________________________________
(кирәклесе астына сызарга)
______________________________________________________________________________
(программаның аталышы, №, һ.б. (төбәк бюджеты өчен)
**Төзелеш төре – яңа, үзгәртеп кору, капремонт** ____________________________________________
(кирәксезен сызып ташларга)
**Төзелешнең торышы**
____________________________________________________________
(башланган булса – нинди стадиядә)
**ПД эшләү елы**_____________________**Төзүне башлау**__________________
**Белдерү – беренче, икенче һ.б.**______________________________________
______________________________________________________________________________
(тискәре бәяләмәнең сәбәбен, № күрсәтергә)

## Башлангыч белешмәләр

____________________№__________**ГПЗУ** ___________________
___________________ ______________________________
______________________ №___________ **раслау турында карар**
______________________________
**Проектлау биреме №**_____________________ ______________________________
**Инженерлык тикшеренүләрен башкару биреме** №______________________
_______________________________
**Техник тикшерү**__________________________________________________________
(үзгәртеп корганда, капремонтлаганда)

## Техник шартлары

**Су белән тәэмин итү һәм канализацияләү** №_________ _________ 201 ел.
**Газ белән тәэмин итү** №__________ _________ 201 ел.
**Җылы белән тәэмин итү** № ________ _____201 ел.
**Элемтә челтәрләре** №__________ _______ 201 ел.
**Электр белән тәэмин итү** № ______ ____ 201 ел.
**Төзекләндерү, явым-төшем һәм эрегән суларны чыгару** № ________ ____ 201 ел.

**Диспетчерлаштыру №________ _______ 201 ел.**

**Экспертиза хакын хисаплау өчен күрсәткечләр**

| | 2001 ел бәяләрендә | **Торак төзелешләре өчен** | |
|---|---|---|---|
| | | Бина периметры буйлап төзелмә мәйданы | Бина мәйданы |
| Гомуми смета бәясе | | | |
| СМР | | | |
| Проект эшләре | | | |
| Тикшеренү эшләре | | | |
| ПИР | | | |

***Тапшырылган белешмәләрнең һәм документларның дөреслеген раслыйм:***

**Мөрәҗәгать итүче вәкиле**
_____________/___________/_______________________________________
(имза) (дата) (Ф.И.А.)
**Экспертиза вәкиле**
_____________/___________/___________________________
(имза) (дата) (Ф.И.А.)

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 6 кушымта

**МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕНЕҢ БЛАНКЫНДА ҖАВАП БИРҮ РӘВЕШЕ ЯИСӘ ПРОЕКТ ОЕШМАСЫ ҖАВАПЛАРЫНА КАРАТА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕНЕҢ ҖАВАП ХАТЫ**

"ТР ДЭББИ" ДАУ "Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе" дәүләт автоном учреждениесе башлыгы М.Х.Салиховка

Чыгу №____ ___________ ел.

Хөрмәтле Мәҗит Хаҗип улы!

Сезгә "..............................." объекты буенча ачыкланган җитешсезлекләргә карата җавапларны юллыйбыз

| Ачыкланган җитешсезлекләр | Мөрәҗәгать итүченең җавабы |
|---|---|
| 1. | 1. Кабул ителә (кабул ителми).<br>Җитешсезлекләр бетерелде ___ бит ___бүлек |
| | |
| | |

ГИП (имза) Ф. И.А.

**Җаваплар белән хат 3 нөсхәдә тапшырыла.**

Җавапларны 10 көн дәвамында әзерләргә һәм тапшырырга кирәк.

Проект документларына һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына карата 7 кушымта

(“ТР ДЭББИ” ДАУ бланкында тутырыла)

“РАСЛЫЙМ”
Башлык
М.Х. Салихов ________________
“____” ______________20___ел.

**УҢАЙ (ТИСКӘРЕ) ЭКСПЕРТИЗА БӘЯЛӘМӘСЕ**

(кирәксезен сызып ташларга)

| № | X | X | - | X | - | X | - | X | X | X | X | - | X | X |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Капиталь төзелеш объекты

________________________________________,
(капиталь төзелеш объектының аталышы, почта (төзелеш) адресы)

Экспертиза объекты

________________________________________
(инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре; проект документлары; проект документлары һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре)

Искәрмәләр:

1. Экспертиза бәяләмәсенең номеры гарәп саннары белән тутырыла һәм түбәндәге структуралы була:

| X | X | - | X | - | X | - | X | - | X | X | X | X | - | X | X |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

беренче ике шакмакта бәяләмәне биргән экспертиза үткәрүче оешма урнашкан Россия Федерациясенең тиешле кадастр округы номеры күрсәтелә;

дүртенче шакмакта экспертиза рәвеше күрсәтелә (дәүләти яки дәүләти булмаган экспертиза);

алтынчы шакмакта экспертиза бәяләмәсенең нәтиҗәсе күрсәтелә (уңай; тискәре – инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең норматив таләпләренә җавап бирмәве; тискәре – проект документларының норматив таләпләренә җавап бирмәве);

сигезенче шакмакта экспертиза объекты турындагы белешмәләр күрсәтелә

(инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре; проект документлары; проект документлары һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре);

унынчы-ундүртенче шакмакларда – бирелгән бәяләмәнең тәртип саны; соңгы ике шакмакта – бәяләмәне бирү елының соңгы ике саны.

Шул ук вакытта:

а) экспертиза рәвешендәге белешмәләр түбәндәгечә рәсмиләштерелә:

дәүләт экспертизасы – 1 саны белән;

дәүләти булмаган экспертиза – 2 саны белән;

б) экспертиза бәяләмәсенең нәтиҗәсе түбәндәгечә рәсмиләштерелә:

уңай бәяләмә – 1 саны белән;

тискәре бәяләмә (инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең норматив таләпләренә җавап бирмәве) – 2 саны белән;

тискәре бәяләмә (проект документларының норматив таләпләргә җавап бирмәве) – 3 саны белән;

в) экпертиза объекты турындагы белешмәләр түбәндәгечә рәсмиләштерелә:

инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре – 1 саны белән;

проект документлары – 2 саны белән;

проект документлары һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре – 3 саны белән;

г) бирелгән бәяләмәнең тәртип саны саннар белән рәсмиләштерелә, алар кырыйдагы уң шакмактан башлап куела, шул ук вакытта буш калган шакмакларга 0 саны куела. Бәяләмәләргә сан кую эзлекле рәвештә башкарыла, календарь елы тәмамлангач ул нульгә әйләндерелә, 0001дән башлана.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

а) экспертиза үткәрү өчен нигезләр (тапшырылган документларның исемлеге, экспертиза үткәрү турындагы шартнамә реквизитлары);

б) экспертиза объекты турында белешмәләр, карала торган документларның (материалларның), мондый документлардагы бүлекләрнең төрен һәм аталышын күрсәтеп;

в) капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре, шулай ук капиталь төзелеш объектының башка техник-икътисади күрсәткечләре;

г) капиталь төзелеш объектының төре, вазифаи билгеләнеше һәм сыйфатлы үзенчәлекләре;

д) проект документларын әзерләүче һәм (яки) инженерлык тикшеренүләрен башкаручы затлар турында идентификация белешмәләре;

е) Мөрәҗәгать итүче, төзүче, техник заказчы турында идентификация белешмәләре;

ж) Мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документлар турында белешмәләр (әгәр дә Мөрәҗәгать итүче төзүче, техник заказчы булмаса);

з) дәүләт экология экспертизасын үткәрү карала торган капиталь төзелеш объектларына карата шундый экспертиза бәяләмәсенең реквизитлары (номеры, бирелү датасы);

и) капиталь төзелеш объектын финанслау чыгынаклары турында белешмәләр;

к) Мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча тапшырылган, капиталь төзелеш объектын, документларны әзерләү эшләрен башкаручыларны, Мөрәҗәгать итүчене, төзүчене, техник заказчыны идентификацияләү өчен кирәкле булган башка белешмәләр.

## 2. Инженерлык тикшеренүләрен башкару, проект документларын эшләү өчен нигезләр

2.1. Инженерлык тикшеренүләрен башкару өчен нигезләр

а) төзүченең яки техник заказчының инженерлык тикшеренүләрен башкаруга карата биреме турында белешмәләр (әгәр дә инженерлык тикшеренүләре шартнамә нигезендә

башкарылган булсалар);

б) инженерлык тикшеренүләре программасы турында белешмәләр;

в) кулланыла торган типик проект документларына карата уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе реквизитлары (номеры, бирелү датасы) (әгәр дә инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәрү өчен мондый бәяләмәне тапшыру таләп ителсә);

г) Мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча тапшырылган, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен әзерләү өчен нигезләрне һәм башлангыч күрсәткечләрне билгели торган башка мәгълүмат.

2.2. Проект документларын эшләү өчен нигезләр

а) төзүченең яки техник заказчының проект документларын эшләү биреме турында белешмәләр (әгәр дә проект документлары шартнамә нигезендә эшләнгән булсалар);

б) территорияне планлаштыру буенча документлар турында (җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты), капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп кору буенча чик параметрлардан тайпылуларга карата рөхсәтләр булу турында белешмәләр;

в) капиталь төзелеш объектын инженерия-техника тәэминаты челтәрләренә тоташтыруның техник шартлары турында белешмәләр;

г) Мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча тапшырылган, проектлау өчен нигезләр, башлангыч күрсәткечләр турында башка мәгълүматлар.

## 3. Карала торган документларны (материалларны) тасвирлау

3.1. Инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен тасвирлау

а) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору планлаштырыла торган территориянең топографик, инженер-геологик, экологик, гидрологик, метеорологик һәм климат шартлары, геологик һәм инженер-геологик процессларның таралу һәм күзәтелү күренешләрен күрсәтеп (карст, силлар, сейсмиклык, авышу процесслары һәм башкалар);

б) башкарылган инженерлык тикшеренүләре төрләре турында белешмәләр;

в) инженерлык тикшеренүләренең составы, күләме һәм аларны башкару методлары турында белешмәләр;

г) экспертизаны үткәрү процессында инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән оператив үзгәрешләр турында белешмәләр;

3.2. Проект документларының техник өлешен тасвирлау

а) проект документларының каралган бүлекләре исемлеге;

б) һәр каралган бүлек буенча төп карарларны (чараларны) тасвирлау;

в) экспертизаны үткәрү процессында проект документларының карала торган бүлекләренә Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән оператив үзгәрешләр турында белешмәләр;

## 4. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча йомгаклар

4.1. Инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең торышы турында нәтиҗәләр

инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә карата туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗәләр.

Һәр туры килмәү турындагы нәтиҗә нигезләнергә тиеш һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең туры килмәү турында нәтиҗә чыгарылган бүлегенә һәм пунктына яки инженерлык тикшеренүләре материалларына күрсәтү;

экспертиза барышында шуңа туры килмәгәнлеге ачыкланган Россия Федерациясе законнары буенча куллануда мәҗбүри булган норматив-хокукый актның яки норматив документның яки аларны куллану нәтиҗәсендә ирекле нигездә техник регламентларның үтәлеше тәэмин ителә торган, стандартлаштыру өлкәсендәге документларга кертелгән стандартлаштыру өлкәсендәге документның (төзүче һәм (яки) техник заказчы тарафыннан мондый документтан файдалану карары кабул ителгән очракта) билгеле бер таләбенә

сылтама (норматив-хокукый актның яки норматив документның яки стандартлаштыру өлкәсе документының бүлегенә, статьясына, пунктына, кызыл юлына күрсәтеп).

4.2. Проект документларының техник өлешенә карата нәтиҗәләр

а) проект документларының шуларга туры килүе бәяләнгән инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә күрсәтү;

б) проект документларының техник өлешенә карата туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗәләр.

Туры килү турында һәр нәтиҗә дәлилләнергә һәм шушы бәяләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алырга тиеш.

4.3. Гомуми нәтиҗәләр

проект документларының һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында йомгак нәтиҗә.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ________ | ____________________ |
| (экспертның вазифасы) | (имзасы) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

____________________

(квалификация аттестатында күрсәтелгән экспертның эшчәнлек юнәлеше)

____________________

(проект документларының яки инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренең бүлеге (бүлекчәсе яки бер өлеше)

Проект документларына һәм (яки)
инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен
күрсәтүнең административ регламентына
Кушымта
(белешмәлек)

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазифаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр урынбасары | (843) 231-14-05 | A.Gatiyatov@tatar.ru |

“Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе” дәүләт автоном учреждениесе

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башлык | (843) 272-04-94 доб. 619 | expertiza-rt@tatar.ru |
| Башлык урынбасары | (843) 272-04-94 доб. 401 | Timur.Zinatullin@tatar.ru |
| Техник хезмәт җитәкчесе | (843) 272-65-14 доб. 209 | Elena.Zhalenkova@tatar.ru |
| Экспертиза хезмәте җитәкчесе | (843) 241-02-19 доб. 204 | Tamara.Salnikova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру башлыгы | 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |